
Вазыйх Фатыйхов
Патша кырмыска




Берзаманны чыкты бәхәс:
— Кем көчле,— дип,— урманда?
Тыныч кына тора бар да,
Аю монда булганда.
Сөялгән иде агачка,
Гүя күкләр күкрәде!

Күтәрде ауган агачны,
Бер тамчы көч түкмәде!
Кем соң керсен бу бәхәскә,
Билгеле, аю көчле.
Җирдән берәү кул күтәрде,
Бик мескен генә төсле.



Әйтте шунда:
— Чынмы ярыш?
Хак булса, көч сынашам!
Үзем кадәр илле йөкне
Күтәрәм мин, ышансаң!
Бизмәнгә менде кырмыска,
Аннан йөге үлчәнде.

Кырмысканың кыланмышын
Йөзләрчә күз күзләде.
Алды-салды иңбашына,
— Ух, — диде дә кырмыска.
— Мин дә көчле! — диде аю,
Кермәк булды ярышка.



Аю менеп баскан иде,
Яртылаш чүкте бизмән.
Чыдамыйча хәтта күчәр
Сынып китәр кире тиздән.
Аюны үлчәделәр, тик
Йөкне генә кем үлчәр?

Илле аю кадәр йөккә
Түзәрме икән күчәр?
Илле бүкән китерделәр,
Җитмәде бу авырлык.
Аю әйткән йөк өчен бит
Кирәк бөтен каенлык.

Эш чыкты барчасына да,
Йөгерешәләр генә.
Бүре килеп тамга салды
Карт бер имән төбенә.
— Имән,— ди ул,— нык таушалган,
Яшисен дә яшәгән.

Төлкегә пычкы бирделәр
Чын корычтан ясалган.
Төлке бит ул хәйләкәр җан,
Озаклап маташмады.
Пычкы теше бу имәнгә
Хәтта эз дә салмады.



Чират китте кулдан-кулга,
Пычкы гел күчеп йөрде.
Карт имән авып киткәнче,
Беләктә көчләр сүнде.
И куаныштылар болар,
Имән авып киткәнгә.

Кабат шобага ташланды,
Кем салыр, дип, бизмәнгә?
Җыйнаулап ябыштылар да
Кузгатып карадылар.
Үлчәү өстенә салганчы,
Кабаттан арыдылар.





Көч-хәл белән салдылар да
Бизмәнне карадылар:
— Йөк бераз артып киткән,— дип,
Граммлап санадылар.
Җыен күтә тамашаны,
Бәхәс кызганнан-кызды.

Тиеннәр өскә сикерде,
Куяннар читкә посты.
Килеп шунда горур гына
Аю йөккә кул салды.
Аның авыр сулавыннан
Урман да шаулап алды.



Тагын бер кат тавыш салды
Йонлач тәпи — пәһлеван.
Кулын селки, кулын уа —
Кулга нәрсәдер булган!
Битен уды, күзен йомды,
Имән астына керде.
Кырмыскага күз ташлады:
— Әйтче миңа да серне?
— Сере бары куәттәдер! —
Кырмысканың шул җавап.
— Күтәрергә! — диде аю.





Күтәрмәсә, эш харап.
Аяклар җәелү булды,
Имән тавыш чыгарды.
Куян буе күтәрелгәч,
Имән бер читкә ауды.
Өнсез торып калды җыен,
Бу нихәл бу, ни булды?
Аю үзе дә аңламый,
Бер аяк бит кысылды.
Җыйналышып көлделәр дә
Имәнне күтәрделәр.





Чайкалып китте гәүдәсе.
— Сынмаган микән? — диләр.
— Килерме кабат имәнгә?—
Пышылдаштылар шулай.
Булдыра алмас, дигән уй
Күпләрдә туды бугай.

Хур булырга теләмичә
Сүз алды аю кабат:
— Күтәрер дә идем йөкне,
Аяк тая бит, харап.
Аю шулай дип әйтте дә
Кырмыскага күз салды.



Йөкне тартырга кирәкне
Кырмыска тиз аңлады.
Башкалар читтә. Катнашмый.
Бәйгедә кабат икәү.
Күпме булдыралсаң, булдыр,
Юк монда тыю, чикләү!
— Авырлыгымнан өч йөзгә
Авыррак йөк кирәк.
Әле Гиннесс китабында
Мондый рекорд бик сирәк!

Йөкне җепкә тактылар да
Кырмыскага бирделәр.
— Күрсәт әйдә куәтеңне,
Булдыралсаң,— диделәр.
Кулга җепне тотты да ул,

Алып очты зур йөкне.
Моны күтмәгән аюның
Тезләре чүгеп китте.
Тезләнгән килеш аюҗан
Җиңелүен белдерде.





Кырмысканы, үзе алып,
Пьедесталга менгерде.
Мондый олы гаделлекне
Аңладылар һәммәсе.
Килеп туды карурманда
Патшалык мәсьәләсе.
Патшаның кем буласына
Нокта куйды тамаша.
Иң егәрле, иң көчле җан —
Кырмыска булды патша!



# Кайда минем оекбашым?

Иртән торсам, оекбаш юк,
Кая киткән, кем алган?!
Төнлә кемдер урлашкан,
Киеп каядыр барган!
Әй эзлибез өй белән,
Бөтенебез җыйнаулап.
Шунда диван астыннан
Песи чыкты мияулап.

Оекбашны песиебез
Урлаган булган икән!
Минем оекбаш өстендә
Бәбие туган икән...



# Әвәли



Малайларга нәрсә соң! —
Тимераяк — аякта,
Кәшәкә — кулларында,
Йөгерәләр тайгакта.
Малайлар алка куа,
Ә Әвәли тик тора.
Әнисеннән чын хоккейчы
Киемнәрен таптыра.
Әвәли озак көтте,
Тәмам тилмереп бетте.



Ул көткәндә, башкалар
Хоккейчы булып бетте.
Ни күрсеннәр, беркөнне
Әвәли басып тора,—
Чын хоккейчы киеменнән!
Тик башын кашып тора.
Ихтыярсыз күз яше
Тамып төште кулына.
Яшел чирәм үскән бит
Шугалак урынында.

3 Я-719




Шулай язган бу тормышта,
Бүленеш һәр тарафта:
Атка авыр йөк тартырга,
Эткә өйне сакларга!
Бергә килеп Ат белән Эт
Берзаман серләшкәннәр.
Уртак фикергә килгәннәр,
Вәгъдәдә берләшкәннәр.
Нигә Атның авыр йөген
Филгә биреп тормаска?!
Ник Төлкене сакчы ясап,
Оя корып куймаска?!



Нигә әле Юлбарыска
Арба тартып йөрмәскә?!
Этнең туганы Бүрегә
Нигә йөгән кимәскә?!
Ат белән Этнең фикерен
Җил ишетеп алган да
Шул көндә үк пышын-пышын
Тараткан бар җиһанга.
Килешмәгән моңа күпләр:
— Ирек кысыла, харап.
Үзгәрергә тиеш,— дип,— без
Кемнең сүзенә карап?!

Фил акланды бер җыенда:
— Өскә печән төясәм,
Тычкан әләксә борынга,
Таулардан тәгәрәсәм?
Төлке кереште хәйләгә:
— Әтәч килеп бәйләнсә;
Тавышым бит бик йомшак,
Хуҗабыз ишетмәсә...
Койрык ояга сыймыйча,
Өшеп өзелеп төшсә;
Койрыксыз төлке булмый, дип,
Миннән һәркайсы көлсә?
Юлбарыс озак уйланган:
— Куәт тә бар, гәүдәм дә.





Мин бит туңам, нишләрмен соң,
Кышлар җитсә әгәр дә?..
Бәхәс бик озак барган —
Ат та, Эт тә бик арган.
Инде өмет сүнгәндә,

Бер үгез аваз салган:
— Мин,— дигән,— алыштырам,
Ат беразга ял итсен.
Тигезсезлек арабызда
Бераз булса да бетсен!




Боз кузгалды диярсең,
Ата каз да гөр килде.
Эт вазифасын үтәргә
Ризалыгын белдерде.
Ата каз эшкә кереште,
Чит-ятларны каптырды.
Аның ничек каңгылдавын
Эт озак тыңлап торды.

Атна-ун көн үтмәгәндер,
Эт төшенде бер хәлгә:
Каз бит төнлә йоклый икән,
Күзләре күрмәгәнгә.
Ачуланып буламыни,—
Каз яхшылык теләде.
Болай килеп чыгасын
Эт бит алдан белмәде.

Ял иттердең бераз, дип,
Казга ул, рәхмәт, диде.
Оясына кире кайтты,
Кабат каешын киде.
Бу көннәрдә Үгез дә
Шактый йөкләр ташыган.
Сорауларның мең дә бере
Үткән аның башыннан.

Текә таудан менгәндә,
Тояклары кителгән.
Алга барасы урында,
Артка таба кителгән.
Арба тагып йөргәнен
Ат җәлләп карап торган.
Аны бәладән коткару
Чарасын уйлап куйган.





Ял иттерден, рәхмәт, диеп,
Кулын куйган йөрәккә:
— Изге җанлы икәнсең,
Синдәй булыр сирәк лә!
Тәртәгә үзе кергән,
Шулай кирәген белгән.
Ни хәл итмәк, табигать

Бу йөкне аңа булгән!
Ат белән Эт фәлсәфәсен
Күпләр әле аңларлар.
Әлеге мәзәк кыйссада,
Бәлки әле, кайберәүләр
Үзләрен дә табарлар.



# Эчтәлек

Патша-кырмыска
Кайда минем оекбашым?
Әвәли
Ат һәм Эт

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)–5
Ф27

**Фатыйхов Вазыйх**

Ф27 Патша-кырмыска: Шигырьләр, әкиятләр.— Казан: Татар. кит.нәшр., 2003.— 24 б.



Рәссамы
*Юлия Щетинкина*

Издание для детей младшего школьного возраста

*Фатыхов Минневазих Хазипович*

**ЦАРЬ-МУРАВЕЙ**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*. Корректоры *Г.Г.Гарифуллина.* Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән. Оригинал макеттан басарга кул куелды 24.10.2003. Форматы $60\times90^{1}/_{8}$. Офсет кәгазе. «Pragmatica» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 3,0. Шартлы буяу-оттиск 14,0. Нәшер-хисап табагы 4,57. Тиражы 5000. Заказ Я-719. Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул.Баумана, 19. «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN 5-298-01354-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2003